КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 7 июль г.Казань № 564

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәренә тиешле елларны эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акча түләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2005 ел, 29 декабрь, 666 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәренә тиешле елларны эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акча түләү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәренә тиешле елларны эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акча түләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2005 ел, 29 декабрь, 666 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 23 декабрь, 1005 нче; 2018 ел, 30 март, 197 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәренә тиешле елларны эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акча түләү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Бер тапкыр бирелә торган бүләкләү күләмен билгеләү өчен дәүләт органы Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына түбәндәге документларны тапшыра:

дәүләт хезмәткәренең айлык акчалата кереме турында белешмә кәгазен;

җитәкче һәм кадрлар хезмәте тарафыннан расланган дәүләт хезмәтендә эш стажы турында белешмә кәгазен;

тиешле рәвештә расланган хезмәт кенәгәсе күчермәсен һәм (яки) Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66[1] статьясы белән билгеләнгән тәртиптә алынган хезмәт эшчәнлеге турындагы мәгълүматларны;

кадрлар хезмәте тарафыннанраслаган хәрби билет (ул дәүләт хезмәткәрендә булганда) күчермәсен;

класслы чин бирү, дәүләт хезмәткәренең айлык акчалата кереме составына керә торган вазыйфаи окладка өстәмәләр билгеләү турындагы боерыклардан өземтәләр;

дәүләт хезмәткәренең эш стажын билгеләү өчен законнар нигезендә кирәкле башка документларны.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин